ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

2024 ел, 17 февраль N 242

"Апас шәһәр тибындагы поселогы"муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 11 октябрендәге 65 номерлы карары белән расланган "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.5 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контроль чаралар үткәрүгә карата үзара хезмәттәшлектән башка әлеге контроль Нигезләмәдә каралган чараны уздыру турында карар кабул итү таләп ителми.»;

4.1.11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4.2.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контрольдә тотыла торган затка контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң, аларны бетерүнең тиешле срокларын, шулай ук федераль законда контроль рәвеше турында каралган башка чараларны күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирергә;»;

4.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4.5.3.Документлар буенча тикшерү үткәрү срогы ун эш көненнән артып китә алмый. Контроль органы контрольдә торучы затка җибәрелгән вакыттан алып документлар тикшерү барышында күрсәтелгән документларны контроль органга тапшырган мизгелгә кадәр карау өчен кирәкле документларны, шулай ук контроль органның контрольдә тотыла торган затка документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында мәгълүмат җибәрелгәннән соң йә шушы документлардагы белешмәләрнең, контроль органдагы документлардагы һәм (яисә) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләрнең туры килмәве турында кирәкле документларны карау өчен тапшырырга һәм, күрсәтелгән контроль аңлатмаларны документлар бирү вакытына кадәр, документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләп чыгару өчен, кирәкле язма аңлатмалар тапшырырга тиеш.»;

4.5.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү, Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктларына туры китереп, прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.»;

4.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа Федераль законның 66 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрү очраклары керми.";

4.7.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.7.8. Рейд тикшерүе, Федераль законның 66 статьясындагы 3, 4, 6, 8 пунктларына, 57 статьясындагы 3 өлешенә һәм 12 өлешенә туры китереп, прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.

Бер җитештерү объектында берничә контрольдә тотылучы зат эшчәнлеге башкарылган очракта, бер контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек итү срогы, әгәр федераль законда контроль рәвеше турында каралган булса, бер эш көненнән артып китәргә мөмкин.";

4.9.3 пунктының икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4.9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4.Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча Федераль законның 90 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый, моңа федераль законда контроль рәвеше турында билгеләнгән очраклар керми.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
"Апас шәһәр тибындагы поселогы"
муниципаль берәмлеге башлыгы
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Апас шәһәр җирлеге Советы Рәисе

А.Г. Җиһаншин